РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ВЕРХНЕСИМЕТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422068, Республика Татарстан, Сабинский район,с.Верхний Симет, ул.Советская, дом 32

тел. (84362) 45-0-19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮГАРЫ СИМЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422068, Татарстан Республикасы, Саба районы, Югары Симет авылы, Совет урамы, 32 йорт
тел. (84362) 45-0-19

e-mail: Bsim.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
11.02.2026

КАРАР
№ 5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 12.11.2025 №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 29.12.2025 ел, №548-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 12.11.2025 ел, №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.9.1 пунктның 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «үз-үзен җайга салучы оешма вәкилләре, әгәр контрольдә тотылучы зат өчен үз-үзен җайга салучы оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса, » сүзләрен өстәргә .

**2.** Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/simet җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**3.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Симет авыл җирлеге башлыгы И.Р.Ахмадуллин